Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кичүчат авыл Советы

КАРАР

16 июль 2024 ел № 101

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл Советының 2022 елның 20 январендагы 33 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл Советы депутаты статусы турындагы нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 15 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә

Кичүчат авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл Советының 2022 елның 20 январендагы 33 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл Советы депутаты статусы турындагы нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүчат авыл Советының 2022 елның 13 июлендәге 46 номерлы, 2023 елның 26 сентябрендәге 78 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада 14 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пункты белән тулыландырырга:

«11.1) чит ил агенты статусын алу;»

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Кичүчат авылы, Юлдаш урамы, 2А йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач (халыкка җиткергәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кичүчат авыл
җирлеге башлыгы вазыйфасын башкаручы Р.Х.Ильясов